**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Урсай торак пунктында гражданнар җыены карары**

**22.12.2021** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан РеспубликасыЗаконының 35 статьясынигезендә,Татарстан Республикасы Зәймуниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсайторак пунктындагражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1.Көндезге бүлектә укучы студентлар, I группа инвалидлар, һәм ялгыз өлкәннәрдән кала, яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең Урсай авылында теркәлгән, балигъ булган һәр гражданга 2022 елда үзара салымны 500 (биш йөз) сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (агач, куаклар кисү)
- зиратны төзекләндерү (агач, куаклар кисү);
- чишмәне төзекләндерү (агач, куаклар кисү), чишмә территориясен киртәләү;
- чишмәгә юл салу;
- мәгълүмат стендын сатып алу һәм урнаштыру.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Урсай
авыл җирлеге башлыгы_______________ Гатина Н.А.